ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2024 г.Казань № 595-149/кс-2024

Алабуга муниципаль районының «Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыяте өчен Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2023 ел, №741-123/кс-2023 карары белән эчәр суга билгеләнгән озак сроклы тарифларны 2025 елга төгәлләштерү һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2023 ел, №741-123/кс-2023 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә эшчәнлек алып баручы оешмаларның инвестиция һәм җитештерү программалары турында» 2013 елның 29 июлендәге 641 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 ел, №468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 18.12.2024 ел, №35-ПР беркетмәсе нигезендә, 2025 елга эчәр суга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулаем керемenә төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районының «Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыяте өчен Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Алабуга муниципаль районының «Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыяте

өчен 2024-2026 елларга эчәр суга тарифлар билгеләү турында» 15.12.2023 ел, №741-123/кс-2023 карары белән эчәр суга билгеләнгән тарифларны 2025 елга төгәлләштереп, 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (кушымтада) бирергә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында төгәлләштерелгән тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Алабуга муниципаль районының «Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыяте өчен 2024-2026 елларга эчәр суга тарифлар билгеләү турында» 15.12.2023 ел, №741-123/кс-2023 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Алабуга муниципаль районының «Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыяте өчен 2024-2026 елларга эчәр суга тарифлар билгеләү һәм җитештерү программасын раслау турында»;

преамбулада «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салуы турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция һәм җитештерү программалары турында» 2013 елның 29 июлендәге 641 номерлы карарлары белән» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 1.1-1.2 пунктлар өстәргә:

«1.1. Әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә «Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» АҖ су белән тәэмин итү өлкәсендәге җитештерү программасын расларга.

1.2. Әлеге карарның 1.1 пункты белән расланган җитештерү программасы 2025 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.»;

4 нче кушымта белән тулыландырырга (кушымта итеп бирелә).

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2023 ел, №741-123/кс-2023 карарына 2 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2024 № 595-149/кс-2024 карары редакциясендә)

2025-2026 елларга* салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ өчен эчәргә яраклы суга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Чор | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Алабуга муниципаль районы | | |
| 1 | «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ | | |
| 1.1 | халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)** | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 53,77 |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 63,20 |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 53,36 |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 55,96 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 44,81 |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 52,67 |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 44,47 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 46,63 |

* 2025-2026 елларга эчәргә яраклы суга тарифларга ел саен төзәтмәләр кертү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары нигезендә уздырыла.
** Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2023 ел, №741-123/кс-2023 карарына 4 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2024 № 595-149/кс-2024 карары редакциясендә)

<table>
<tr><td colspan="6">Оешманың җитештерү программасы</td></tr>
<tr><td colspan="6">1 нче бүлек. Җитештерү программасы паспорты</td></tr>
<tr><td colspan="2">Җайга салынулы оешма</td><td colspan="4">«Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ</td></tr>
<tr><td colspan="2">Урнашу урыны</td><td colspan="4">423601, ТР, Алабуга районы, Ш-2 урамы (Алабуга МИЗ тер.), 4/1</td></tr>
<tr><td colspan="2">Җайга салучы вәкаләтле орган</td><td colspan="4">Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты</td></tr>
<tr><td colspan="2">Урнашу урыны</td><td colspan="4">420015, Казан ш., Карл Маркс ур., 66 й.</td></tr>
<tr><td colspan="2">Җитештерү программасын гамәлгә ашыру чоры</td><td>башлана</td><td>01.01.2025</td><td>тәмамлана</td><td>31.12.2026</td></tr>
<tr><td colspan="6">2 нче бүлек. Су белән тәэмин итүнең һәм ташландык суларны агызуның үзәкләштерелгән системалары объектларын ремонтлау чаралары, эчә торган суның сыйфатын һәм агып төшүче суларны чистарту сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру, шул исәптән транспортировкада су югалтуларын киметү чаралары исемлеге</td></tr>
<tr><td rowspan="2">№</td><td rowspan="2">Атамасы</td><td rowspan="2">Үлчәү берәмлеге</td><td colspan="3">Гамәлгә ашыруга финанс ихтыяҗлары</td></tr>
<tr><td>2025</td><td colspan="2">2026</td></tr>
<tr><td colspan="6">1ХВС – Эчәр суга тариф – су белән тәэмин итү</td></tr>
<tr><td>1</td><td>Агымдагы ремонт</td><td>мең сум</td><td>40 173,04</td><td colspan="2">41 469,68</td></tr>
<tr><td>2</td><td>Капиталь ремонт</td><td>мең сум</td><td>5 624,52</td><td colspan="2">5 806,06</td></tr>
<tr><td>3</td><td>Башка чаралар, шул исәптән эчә торган суларны чистарту сыйфатын яхшыртуга, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чаралар</td><td>мең сум</td><td>0,00</td><td colspan="2">0,00</td></tr>
<tr><td colspan="6">3 нче бүлек. Су бирү күләме/Кабул ителгән су</td></tr>
<tr><td colspan="6">1ХВС – Эчәр суга тариф – су белән тәэмин итү</td></tr>
<tr><td rowspan="2">№</td><td rowspan="2">Җитештерү эшчәнлеге күрсәткечләре</td><td rowspan="2">Үлчәү берәмлеге</td><td colspan="3">Күрсәткеч зурлыгы</td></tr>
<tr><td>2025</td><td colspan="2">2026</td></tr>
<tr><td>1</td><td>Күтәрелгән су күләме</td><td>мең м3</td><td>8 606,41</td><td colspan="2">8 535,52</td></tr>
<tr><td>2</td><td>Технологик ихтыяҗларга су күләме</td><td>мең м3</td><td>0,00</td><td colspan="2">0,00</td></tr>
<tr><td>3</td><td>Читтән алынган су күләме</td><td>мең м3</td><td>0,00</td><td colspan="2">0,00</td></tr>
</table>

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4 | Чистарту корылмалары аша үткәрелгән су күләме | мең м3 | 8 606,41 | 8 606,41 |
| 5 | Челтәргә бирелгән су | мең м3 | 8 606,41 | 8 535,52 |
| 6 | Су югалту күләме | мең м3 | 1 106,78 | 1 097,67 |
| 7 | Су җибәрелгән, барлыгы | мең м3 | 7 123,50 | 7 061,73 |
| 8 | Предприятие ихтыяҗларына тотыла торган су күләме | мең м3 | 524,25 | 524,25 |
| 9 | Кулланучыларга су җибәрү (сату), барлыгы, шул исәптән: | мең м3 | 6 599,25 | 6 537,49 |
| 9.1 | су белән тәэмин итүнең башка оешмаларына | мең м3 | 0,00 | 0,00 |
| 9.2 | халыкка | мең м3 | 2 537,25 | 2 232,78 |
| 9.3 | бюджет оешмаларына | мең м3 | 270,00 | 270,00 |
| 9.4 | башка кулланучыларга | мең м3 | 3 792,00 | 4 034,70 |

**4 нче бүлек. Җитештерү программасын гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс ихтыяҗлары күләме**

| № | Күрсәткеч | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч зурлыгы | |
|---|---|---|---|---|
| | | | **2025** | **2026** |
| 1 | Җитештерү чыгымнары | мең сум | 235 055,01 | 23 831,34 |
| 1.1 | Хезмәт өчен түләү һәм төп җитештерү персоналының социаль ихтыяҗларына түләүләр чыгымнары | мең сум | 88 052,78 | 90 894,82 |
| 2 | Ремонт чыгымнары | мең сум | 45 797,56 | 47 275,75 |
| 3 | Административ чыгымнар | мең сум | 0,00 | 0,00 |
| 4 | Сату чыгымнары | мең сум | 0,00 | 0,00 |
| 5 | Амортизация | мең сум | 26 946,67 | 28 849,21 |
| 6 | Аренда һәм концессия түләүләре, лизинг түләүләре | мең сум | 0,00 | 0,00 |
| 7 | Салымнар һәм җыемнар | мең сум | 8 727,36 | 9 536,77 |
| 8 | Норматив табыш | мең сум | 17 711,93 | 11 709,80 |
| 8.1 | Капиталь чыгымнар | мең сум | 6 566,73 | 0,00 |
| 9 | Гарантияләүче оешманың исәпләмә эшкуарлык табышы | мең сум | 15 826,33 | 16 469,17 |
| 10 | Узган чорларның алынмаган керемнәре / чыгымнары | мең сум | 0,00 | 0,00 |
| 10.1 | Узган чорда тарифлар билгеләгәндә тарифларны җайга салу органы тарафыннан исәпкә алынмаган икътисадый нигезләнгән чыгымнар | мең сум | 0,00 | 0,00 |
| 10.2 | Җайга салуның узган чорларында алынмаган керемнәр | мең сум | 0,00 | 0,00 |
| 10.3 | Акча җитмәүне каплауга юнәлдерелгән заем акчаларына һәм үз акчаларына хезмәт күрсәтүгә бәйле чыгымнар | мең сум | 0,00 | 0,00 |
| 11 | Җайга салуның узган чорларының икътисадый яктан нигезләнмәгән керемнәре / чыгымнары | мең сум | 2 857,71 | 2 857,71 |
| 12 | Кирәкле тулаем табыш | мең сум | 347 207,14 | 354 704,67 |

**5 нче бүлек. Җитештерү программасы чараларын гамәлгә ашыру графигы**

| № | Чараның атамасы | План чоры |
|---|---|---|
| 1 | Су белән тәэмин итү челтәрләрен капиталь ремонтлау | 2025-2026 |

**6 нчы бүлек. Су белән тәэмин итүнең һәм ташландык суларны агызуның үзәкләштерелгән системалары объектларының ышанычлылыгы, сыйфаты һәм энергетик нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләре**

| № | Күрсәткеч | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч зурлыгы | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 2025 | 2026 |
| 1ХВС – Эчәр суга тариф – су белән тәэмин итү | | | | |
| 1 | Эчә торган суның сыйфат күрсәткечләре | | | |
| 1.1 | Дпс – Су белән тәэмин итү чыганакларыннан, сууткәргеч станцияләреннән яисә үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системасының башка объектларыннан бүлү сууткәргеч челтәренә билгеләнгән таләпләргә туры килми торган эчәр су пробаларының эчәр су сыйфатын производство тикшереп торуы нәтиҗәләре буенча алынган пробаларның гомуми күләмендә бирелә торган эчәр су пробалары өлеше | % | 0,00 | 0,00 |
| 1.2 | Дпрс – Бүлүче сууткәргеч челтәрендә эчәргә яраклы суның сыйфатын производство тикшереп торуы нәтиҗәләре буенча алынган пробаларның гомуми күләмендә билгеләнгән таләпләргә туры килми торган эчәргә яраклы су пробалары өлеше | % | 0,00 | 0,00 |
| 2 | Су белән тәэмин итүнең ышанычлылыгы һәм өзлексезлеге күрсәткечләре | | | |
| 2.1 | Пн – Салкын су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасы объектларындагы аварияләр, зарарланулар һәм башка технологик хокук бозулар нәтиҗәсендә салкын су белән тәэмин итү буенча салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешманың йөкләмәләрен үтәү урыннарында салкын су белән тәэмин итү шартнамәсендә, бердәй су белән тәэмин итү һәм су түгү шартнамәсендә яисә салкын су ташу шартнамәсендә билгеләнгән өзеклекләр саны салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешманың су белән тәэмин итүләре, елга сууткәргеч челтәренең озынлыгын исәпләп, бер елга | бер./км | - | - |
| 3 | Энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | | | |
| 3.1 | Дпв – сууткәргеч челтәренә бирелгән суның гомуми күләмендә суны транспортировкалаганда үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларында су югалтулар өлеше | % | 12,86 | 12,86 |
| 3.2 | Урп – Эчә торган су әзерләүнең технологик процессында кулланыла торган электр энергиясе челтәргә җибәрелә торган су күләме берәмлегенә чагыштырма чыгымы | кВт*сәг/куб.м | 1,050 | 1,050 |
| 3.3 | Урп – Эчә торган суны транспортлауның технологик процессында кулланыла торган электр энергиясенең транспортлана торган эчә торган су күләме берәмлегенә чагыштырма чыгымы | кВт*сәг/куб.м | | |

**7 нче бүлек. Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системалары объектларының ышанычлылыгы, сыйфаты һәм энергетик нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләренең һәм җитештерү программасын гамәлгә ашыру чыгымнарының аның гамәлдә булу чоры дәвамында үзгәреш динамикасын чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла торган җитештерү программасының нәтиҗәлелеген исәпләү**

| № | Күрсәткеч | Үлчәү берәмлеге | Планлаштырыла торган чор күрсәткече зурлыгы | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 2025 | 2026 |
| 1ХВС – Эчәр суга тариф – су белән тәэмин итү | | | | |
| | Үзгәреш динамикасын чагыштыру | % | Ышанычлылык, сыйфат һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләре үзгәрешсез билгеләнә | |

**8 нче бүлек. Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турында хисап**

| | |
|---|---|
| Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турындагы хисап оешманың 2023 елгы финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләре турындагы хисабы составында бирелгән | |
| **9 нчы бүлек. Абонентларга хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар** | |
| № | Абонентларга хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар каралмаган |